ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 327 от «03» 09 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 28 маендагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге №177-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләр турында» 393 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 28 маендагы 195 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юк дип тану һәм аларны кичерү турындагы карарлар кабул итү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1.Тәртипнең 2.1 пунктында:

а)2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) "Бөлгенлек (банкротлык) турында" 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын-күрсәтелгән Федераль закон нигезендә түләү бурычын үтәүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә тәмамлау;";

б) 2.1 пунктчаны үз көчен югалтты дип танырга;

в) 4 һәм 5 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) штрафлар рәвешендә җәзага тартылган яисә суд тарафыннан карар кабул ителгән, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта;

0000012340

банкротлык турындагы эштә кулланыла торган реорганизация процедурасын уздыручы, ликвидацияләү яки процедурада булган бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта;

5) “Башкару эшчәнлеге турында” 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигезләмә буенча башкарма документны түләтүчегә кайтарганда, күләме банкротлык турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычка карата таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килү датасыннан биш елдан артык узган булса, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма документны кире кайтару турында карар чыгару;

г) түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункт өстәргә:

"5.1) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителү;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы сайтында (http://madysh.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Р.М.Никифоров